ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

24.11.2021                д. им. М. Вахитова                № 39

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июленнән Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

Карар бирәм:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында 4 декабрь көнне 09.00 сәгатькә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында 4 декабрь көнне 11.00 сәгатькә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында 4 декабрь көнне 13.00 сәгатькә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында 4 декабрь көнне 15.00 сәгатькә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Яңа урам халкы

2 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Үзәк урам халкы

3 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Югары урам, Яшьләр урамы халкы

4 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Мәктәп тыкрыгы халкы.

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 елда Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл Мулланур Вахитов исемендәге авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Мулланур Вахитов исемендәге авылда су алу зонасын төзекләндерү:
« ӘЙЕ» «ЮК»

7.Гражданнар җыеннарын уздырырга:

1 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Яңа урам буенча 6 нчы йорт янында

2 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Үзәк урамы буенча 25 нче йорт янында

3 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Яшьләр урамы 5 йорт янында

4 этап: Мулланур Вахитов исемендәге авыл Мәктәп тыкрыгы буенча 2 нче йорт янында

8. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф. Р. Кәримов